Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Богородский авыл җирлеге башкарма комитеты

# КАРАР

7 сентябрь, 2022 ел № 26

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Богородский авыл җирлеге Генераль планына үзгәрешләр кертү проектын әзерләү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Богородский авыл җирлеге уставы нигезендә, Питрәч муниципаль районы башлыгының 2022 елның 07 сентябрендәге Исх-783 номерлы хаты нигезендә, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, Россия Федерациясе Федераль законы нигезендә **Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Богородский авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирә:**

1. «Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Богородский авыл җирлегенең генераль планын раслау турында» Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советының 2020 елның 23 июнендәге 268 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Богородский авыл җирлегенең генераль планына үзгәрешләр кертү проектын әзерләүгә керешергә.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районы рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).
3. Әлеге карар аңа кул куйган көннән үз көченә керә.
4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Питрәч муниципаль районы
Богородский авыл җирлеге башлыгы М.Н. Бикбов